ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
«НОВОЧЕРШИЛИНСКОЕ
СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»
ЛЕНИНОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЛЕНИНОГОРСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «ЯҢА
ЧЫРШЫЛЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ
БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

2022 елның 31 гыйнвары Яңа Чыршылы п. № 1

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетында җирләү буенча хезмәт күрсәтүләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе коэффициентын раслау турында» 2022 елның 27 гыйнварындагы 57 номерлы карары нигезендә, «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге башкарма комитетында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге буенча күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен, 1, 2 нче кушымталар нигезендә, 6 964,68 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.

2. Татарстан республикасы Лениногорск муниципаль районы «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында»гы 2021 елның 10 февралендәге 1 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карар 2021 елның 1 февраленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарны Лениногорск муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга (pravo.tatarstan.ru).

5.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Татарстан
Лениногорск муниципаль райны
«Яңа Чыршылы авыл җирлеге»

муниципаль берәмлеге башлыгы Р.Ә.Мөхәмәтшина

«Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2022 елның 31 гыйнварындагы 1 номерлы карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетында җирләү буенча (туганнары булган) хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәясе 2022 елның 1 февраленнән

| Хезмәтләрнең исеме | Хезмәтләрнең бәясе, сумн. |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2 632,66 |
| 3. Мәрхүмнең гаүдәсен (җәсәдләрен) зиратка китерү | 1 323,28 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм җирләү) | 3 008,74 |
| Барлыгы | **6 964,68** |

«Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2022 елның 31 гыйнварындагы 1 номерлы карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Яңа Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча (туганнары булган) хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәясе 2022 елның 1 февраленнән

| Хезмәтләрнең исеме | Хезмәтләрнең бәясе, сумн. |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 868,78 |
| 3. Мәрхүмнең гаүдәсен (җәсәдләрен) зиратка китерү | 1 763,88 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм җирләү) | 1 323,28 |
| Барлыгы | 3 008,74 |
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | **6 964,68** |